ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

07.09.2021 № 1258

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә «Мобиль укытучы» проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 8 апрелендәге 483 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Алабуга муниципаль районының ерак торак пунктларында урнашкан мәгариф учреждениеләрендә (оешмаларда) педагогик эшчәнлек алып баручы педагогик хезмәткәрләрне автомобильләр белән тәэмин итү максатларында, Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «Алабуга муниципаль районы территориясендә «Мобиль укытучы» проектын гамәлгә ашыру турында» 2021 елның 8 апрелендәге 483 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның 5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«5. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хуҗалык идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе бюджетында финанслауны тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

1.2. «Алабуга муниципаль районы территориясендә «Мобиль укытучы» проектын гамәлгә ашыру тәртибендәге 5, 6, 7 бүлекләрдә текст буенча «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты» сүзләрен «Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты каршындагы хуҗалык идарәсе» муниципаль автоном учреждениесе» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Л.Р. Яһудинага йөкләргә.

Җитәкче Л.Ф. Нургаянов